Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кара Күл торак пунктында
гражданнар җыены КАРАРЫ

«08» ноябрь 2021ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кара Күл торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кара Күл торак пункты территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 6000 (алты мең) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- авыл җирлегенең торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын, шул исәптән грунт-вак таш салу, Кара Күл торак пунктында төзелеш контроле өчен түләү белән карап тоту һәм ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Авдеева